Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Бөгелмә муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Бөгелмә муниципаль районы составындагы "Карабаш шәһәр тибындагы поселогы" һәм "Зур Федоровка авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**

Бөгелмә муниципаль районы составына керүче "Зеленая Роща авыл җирлеге" һәм "Кече Бөгелмә авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен "Зеленая Роща авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең "Бөгелмә шәһәре" муниципаль берәмлеге, "Березовка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге һәм "Кече Бөгелмә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә урнашкан басу аша кишәрлеген "Кече Бөгелмә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе составына кертү юлы белән үзгәртергә.

**3 статья**

"Бөгелмә муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 8 (IV өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бөгелмә муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Бөгелмә муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

# <u>карта-схемасы</u>




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 40(25)-41 | - Самара өлкәсе |
| 32(24)-41 | - Оренбург өлкәсе |
| 40(25)-1(76) | - Лениногорск муниципаль районы |
| 1(76)-3(73) | - Әлмәт муниципаль районы |
| 3(73)-28(74) | - Азнакай муниципаль районы |
| 28(74)-30(75) | - Ютазы муниципаль районы |
| 30(75)-32(24) | - Баулы муниципаль районы |

"Бөгелмә муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Бөгелмә шәһәре |
| 2 | Карабаш шәһәр тибындагы поселогы |
| 3 | Акбаш авыл җирлеге |
| 4 | Березовка авыл җирлеге |
| 5 | Зур Федоровка авыл җирлеге |
| 6 | Восточный авыл җирлеге |
| 7 | Вязовка авыл җирлеге |
| 8 | Зеленая Роща авыл җирлеге |
| 9 | Ключи авыл җирлеге |
| 10 | Кодаш авыл җирлеге |
| 11 | Кече Бөгелмә авыл җирлеге |
| 12 | Наратлы авыл җирлеге |
| 13 | Яңа Александровка авыл җирлеге |
| 14 | Яңа Сумароков авыл җирлеге |
| 15 | Петровка авыл җирлеге |
| 16 | Подгорный авыл җирлеге |
| 17 | Спас авыл җирлеге |
| 18 | Иске Исаково авыл җирлеге |
| 19 | Татар Димескәе авыл җирлеге"; |

2) 3 нче кушымтада:

а) дүртенче абзацта "Зеленая Роща авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге" сүзләрен "Кече Бөгелмә авыл җирлеге" сүзләренә алмаштырырга;

б) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бөгелмә шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге Кече Бөгелмә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 20 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 400 м көнчыгышка таба күмәк бакчаларның төньяк чиге буйлап, шуннан соң "Бөгелмә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөгелмә участок урманчылыгындагы 96 нчы урман кварталының аерым торган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 370 м төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, шушы урман кварталының төньяк чиге буйлап 110 м көньяк-көнчыгышка таба, 96 нчы урман кварталының аерым торган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 280 м бара, шуннан соң шушы урман кварталы буенча 80 м көньяк-көнчыгышка таба, 110 м көньякка таба, 230 м көньяк-көнбатышка таба һәм 200 м көньякка таба Казачья елгасына кадәр уза, бу елга агымы буенча аска таба 2,0 км бара, алга таба 100 м төньякка таба 96 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап,

Казан – Оренбург автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба бара һәм, сынык сызык ясап, 1,2 км Кече Бөгелмә авылының көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба 800 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Бөгелмә – Ютазы автомобиль юлына кадәр, 800 м көньяк-көнбатышка таба бу автомобиль юлы буйлап "Казан – Оренбург" – Кече Бөгелмә автомобиль юлына кадәр уза, 700 м төньяк-көнбатышка таба бу автомобиль юлы буйлап бара, аннары 300 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 100 м көньяк-көнчыгышка таба сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, шуннан соң 100 м төньяк-көнчыгышка таба күмәк бакчаларның көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 200 м төньяк-көнбатышка таба сәнәгать объектының көнбатыш чиге буйлап һәм 470 м төньякка таба сәнәгать объектының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньякка таба, 50 м көнчыгышка таба, 100 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 100 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары 300 м төньяк-көнбатышка таба күмәк бакчаларның көньяк-көнбатыш чиге буйлап инешкә кадәр бара, бу инеш агымы буенча 350 м аска таба уза, алга таба, сынык сызык ясап, 500 м төньяк-көнчыгышка таба күмәк бакчаларның көнбатыш чиге буйлап 45 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

в) сигезенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 4 нче кушымтада:

а) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Карабаш шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге чиге Зур Федоровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 5 нче тоташу ноктасыннан алып 2,9 км көньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, плотинаны кисеп үтеп, 550 м көнбатышка таба буа буйлап бара, шуннан соң шул ук юнәлештә 250 м чокырланган җирләрнең көньяк чиге буйлап "Победа – ПАТП ял базасы" автомобиль юлына кадәр уза, 650 м бу автомобиль юлы буйлап "Победа – "Буревестник" ял базасы" автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба 150 м төньяк-көнбатышка таба бу автомобиль юлы буйлап, Күзәмбай елгасын кисеп үтеп, Ялшан елгасына кадәр уза, бу елга агымы буенча өскә таба 1,16 км бара, аннары 2,3 км көньяк-көнбатыш юнәлештә Победа – Елховка автомобиль юлы буйлап Елховка инешенә кадәр уза, бу инеш агымы буенча 470 м өскә таба автомобиль юлына кадәр бара, шуннан соң 85 м төньяк-көнбатышка таба һәм, сынык сызык ясап, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба 950 м "Лениногорск урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лениногорск участок урманчылыгындагы 3 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап "Карабаш шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге, Березовка һәм Зур Федоровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Елховка авылыннан 500 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 9 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.";

б) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Карабаш шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге чиге Березовка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 9 нчы тоташу ноктасыннан алып 1,1 км көньяк-көнбатышка таба, Лениногорск – Азнакай автомобиль юлын кисеп үтеп, "Лениногорск урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лениногорск участок урманчылыгындагы 3 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, бу урман кварталының көньяк чиге буйлап 190 м көнбатышка таба һәм 130 м төньяк-көнбатышка таба, Лениногорск – Азнакай автомобиль юлын кисеп үтеп, "Карабаш шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге, Березовка авыл җирлеге һәм Лениногорск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Елховка авылыннан 1,5 км көньякта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) сигезенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

4) 6 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта "Зеленая Роща," сүзләрен төшереп калдырырга;

б) бишенче һәм алтынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Березовка авыл җирлеге чиге Зур Федоровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә "Карабаш шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге, Березовка һәм Зур Федоровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Елховка авылыннан 500 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 9 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 470 м төньяк-көнбатышка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 475 м көнчыгышка таба уза, аннары 1,14 км көньяк-көнчыгыш юнәлештә "Лениногорск урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лениногорск участок урманчылыгындагы 4 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, Лениногорск – Азнакай автомобиль юлын кисеп үтеп, 425 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба шул ук юнәлештә бу урманчылыктагы 4 нче урман кварталының аерым торган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 1,1 км һәм төньяк-көнчыгыш юнәлештә көнчыгыш чиге буйлап 1,5 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,9 км төньяк-көнчыгышка таба, инешләрне кисеп үтеп, 120 м төньякка таба, 220 м көнчыгышка таба һәм 250 м көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң көньяк-көнчыгыш юнәлештә "Бөгелмә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөгелмә участок урманчылыгындагы 3 нче урман кварталының аерым торган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 630 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 440 м көнчыгышка таба, алга таба шул ук юнәлештә бу урманчылыктагы 3 нче урман кварталының аерым торган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 270 м һәм 640 м төньяк-көнчыгышка таба төньяк-көнбатыш чиге буйлап Березовка, Зур Федоровка авыл җирлекләре һәм Азнакай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Победа поселогыннан 3,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Березовка авыл җирлеге чиге "Карабаш шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 9 нчы тоташу ноктасыннан алып 1,1 км көньяк-көнбатышка таба, Лениногорск – Азнакай автомобиль юлын кисеп үтеп,

"Лениногорск урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лениногорск участок урманчылыгындагы 3 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, бу урман кварталының көньяк чиге буйлап 190 м көнбатышка таба һәм 130 м төньяк-көнбатышка таба, Лениногорск – Азнакай автомобиль юлын кисеп үтеп, 10 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Березовка авыл җирлеге чиге Кече Бөгелмә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып Зәй елгасы агымы буенча өскә таба 1,9 км Бөгелмә елгасы белән кушылган җиргә кадәр уза, аннары Бөгелмә елгасы агымы буенча өскә таба 9,7 км "Бөгелмә шәһәре" муниципаль берәмлеге, Березовка һәм Кече Бөгелмә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Бөгелмә елгасы үзәнендә Кече Бөгелмә авылыннан 2,5 км төньяк-көнбатышта урнашкан 45 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

г) унберенче һәм ундүртенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

5) 7 нче кушымтада:

а) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Зур Федоровка авыл җирлеге чиге Березовка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә "Карабаш шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге, Березовка һәм Зур Федоровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Елховка авылыннан 500 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 9 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 470 м төньяк-көнбатышка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 475 м көнчыгышка таба уза, аннары 1,14 км көньяк-көнчыгыш юнәлештә "Лениногорск урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лениногорск участок урманчылыгындагы 4 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, Лениногорск – Азнакай автомобиль юлын кисеп үтеп, 425 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба шул ук юнәлештә бу урманчылыктагы 4 нче урман кварталының аерым торган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 1,1 км һәм төньяк-көнчыгыш юнәлештә көнчыгыш чиге буйлап 1,5 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,9 км төньяк-көнчыгышка таба, инешләрне кисеп үтеп, 120 м төньякка таба, 220 м көнчыгышка таба һәм 250 м көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң көньяк-көнчыгыш юнәлештә "Бөгелмә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөгелмә участок урманчылыгындагы 3 нче урман кварталының аерым торган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 630 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 440 м көнчыгышка таба, алга таба шул ук юнәлештә бу урманчылыктагы 3 нче урман кварталының аерым торган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 270 м һәм 640 м төньяк-көнчыгышка таба төньяк-көнбатыш чиге буйлап 6 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Зур Федоровка авыл җирлеге чиге "Карабаш шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 5 нче тоташу ноктасыннан алып 2,9 км

көньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, плотинаны кисеп үтеп, 550 м көнбатышка таба буа буйлап бара, шуннан соң шул ук юнәлештә 250 м чокырланган җирләрнең көньяк чиге буйлап "Победа – ПАТП ял базасы" автомобиль юлына кадәр уза, 650 м бу автомобиль юлы буйлап "Победа – "Буревестник" ял базасы" автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба 150 м төньяк-көнбатышка таба бу автомобиль юлы буйлап, Күзәмбай елгасын кисеп үтеп, Ялшан елгасына кадәр уза, бу елга агымы буенча өскә таба 1,16 км бара, аннары 2,3 км көньяк-көнбатыш юнәлештә Победа – Елховка автомобиль юлы буйлап Елховка инешенә кадәр уза, бу инеш агымы буенча 470 м өскә таба автомобиль юлына кадәр бара, шуннан соң 85 м төньяк-көнбатышка таба һәм, сынык сызык ясап, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба 950 м "Лениногорск урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лениногорск участок урманчылыгындагы 3 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 9 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.";

в) җиденче – тугызынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

6) 10 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта "Березовка," сүзен төшереп калдырырга;

б) унынчы – унөченче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

7) 13 нче кушымтада:

а) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Кече Бөгелмә авыл җирлеге чиге Березовка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Березовка, Кече Бөгелмә һәм Яңа Александровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Зәй елгасы үзәнендә Кече Бөгелмә авылыннан 150 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып Зәй елгасы агымы буенча өскә таба 1,9 км Бөгелмә елгасы белән кушылган җиргә кадәр уза, аннары Бөгелмә елгасы агымы буенча өскә таба 9,7 км "Бөгелмә шәһәре" муниципаль берәмлеге, Березовка һәм Кече Бөгелмә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Бөгелмә елгасы үзәнендә Кече Бөгелмә авылыннан 2,5 км төньяк-көнбатышта урнашкан 45 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

б) унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Кече Бөгелмә авыл җирлеге чиге "Бөгелмә шәһәре" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 20 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 400 м көнчыгышка таба күмәк бакчаларның төньяк чиге буйлап, шуннан соң "Бөгелмә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөгелмә участок урманчылыгындагы 96 нчы урман кварталының аерым торган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 370 м төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, шушы

урман кварталының төньяк чиге буйлап 110 м көньяк-көнчыгышка таба, 96 нчы урман кварталының аерым торган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 280 м бара, шуннан соң шушы урман кварталы буенча 80 м көньяк-көнчыгышка таба, 110 м көньякка таба, 230 м көньяк-көнбатышка таба һәм 200 м көньякка таба Казачья елгасына кадәр уза, бу елга агымы буенча аска таба 2,0 км бара, алга таба 100 м төньякка таба 96 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Казан – Оренбург автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба бара һәм, сынык сызык ясап, 1,2 км Кече Бөгелмә авылының көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба 800 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Бөгелмә – Ютазы автомобиль юлына кадәр, 800 м көньяк-көнбатышка таба бу автомобиль юлы буйлап "Казан – Оренбург" – Кече Бөгелмә автомобиль юлына кадәр уза, 700 м төньяк-көнбатышка таба бу автомобиль юлы буйлап бара, аннары 300 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 100 м көньяк-көнчыгышка таба сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, шуннан соң 100 м төньяк-көнчыгышка таба күмәк бакчаларның көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 200 м төньяк-көнбатышка таба сәнәгать объектының көнбатыш чиге буйлап һәм 470 м төньякка таба сәнәгать объектының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньякка таба, 50 м көнчыгышка таба, 100 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 100 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары 300 м төньяк-көнбатышка таба күмәк бакчаларның көньяк-көнбатыш чиге буйлап инешкә кадәр бара, бу инеш агымы буенча 350 м аска таба уза, алга таба, сынык сызык ясап, 500 м төньяк-көнчыгышка таба күмәк бакчаларның көнбатыш чиге буйлап 45 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

в) уникенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 22 мае
№ 32-ТРЗ

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

# Чикләре әлеге Закон нигезендә үзгәрүче муниципаль берәмлекләрнең территорияләре <u>карта-схемасы</u>




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
- 10 - тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

I – Зур Федоровка авыл җирлеге территориясе составына кертелүче «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе

II – Кече Бөгелмә авыл җирлеге территориясе составына кертелүче Зеленая Роща авыл җирлеге территориясе

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 40(25)-41 | - Самара өлкәсе |
| 32(24)-41 | - Оренбург өлкәсе |
| 40(25)-1(76) | - Лениногорск муниципаль районы |
| 1(76)-3(73) | - Әлмәт муниципаль районы |
| 3(73)-28(74) | - Азнакай муниципаль районы |
| 28(74)-30(75) | - Ютазы муниципаль районы |
| 30(75)-32(24) | - Баулы муниципаль районы |